КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 сентябрь г.Казань № 763

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 октябрь, 741 нче; 2016 ел, 20 февраль, 104 нче; 2016 ел, 26 май, 354 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 832 нче; 2017 ел, 26 май, 311 нче; 2018 ел, 26 март, 174 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1, 4, 5 нче пунктларда «2015 – 2020» саннарын «2015 – 2021» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2015 – 2020» саннарын «2015 – 2021» саннарына алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2015 – 2020» саннарын «2015 – 2021» саннарына алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлында «2015 – 2020» саннарын «2015 – 2021» саннарына алыштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="9">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="2">Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 49,4412 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(млн.сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>5,615</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>4,37</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>4,915</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>8,1529</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>8,7141</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>8,8371</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>8,8371</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2">Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш»;</td></tr>
</table>

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру буенча көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлының беренче абзацында «2020 ел ахырына» сүзләрен «2021 ел ахырына» сүзләренә алыштырырга;

Программаның II бүлегендә:

унөченче абзацта «2020 ел ахырына» сүзләрен «2021 ел ахырына» сүзләренә алыштырырга;

утызынчы абзацта «2015 – 2020» саннарын «2015 – 2021» саннарына алыштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2015 – 2021 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 49,4412 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән:

(млн.сум)

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме |
|---|---|
| 2015 | 5,615 |
| 2016 | 4,37 |
| 2017 | 4,915 |
| 2018 | 8,1529 |
| 2019 | 8,7141 |
| 2020 | 8,8371 |
| 2021 | 8,8371 |

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Моннан тыш программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны үтәүчеләрнең төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчадан файдалану күздә тотыла.»;

Программаның IV бүлегендәге дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы еллык хисапны (алга таба – еллык хисап) Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, үтәүчедәшләр белән берлектә, хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Премьер-министрына кертә. Еллык хисап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында «Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштырыла.»;

Программаның V бүлегендәге беренче, икенче, тугызынчы абзацларында «2020 елга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алыштырырга;

Программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин